Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Шәле авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Шәле авыл җирлеге башлыгы

# КАРАРЫ

12 октябрь, 2022 ел № 4

Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге Шәле торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге уставының 23 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясе өлешендә) гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы 2019 елның 08 ноябрендәге 59 номерлы (2021 елның 14 декабрендәге 33 номерлы карар белән расланган үзгәрешләр белән) Шәле авыл җирлеге Советы карары нигезендә **карар чыгарам:**

1. Шәле авыл җирлегендә түбәндәге торак пунктларда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләргә:

1.1. Шәле авылында. Халык җыенын 8 этапта үткәрергә:

- халык җыенының беренче этабын 2022 елның 25 октябрендә 10 сәгать 00 минутта Тукай урамы, 16 йорт янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Урман урамы, Яшьләр урамы, Таулы урамы, Тау асты, Тукай урамының 1 - 61 номерлы йортлар буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;
- халык җыенының икенче этабын 2022 елның 25 октябрендә 12 сәгать 30 минутта Таҗиев урамы, 16 йорт, мәктәп бинасы янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Тукай урамының 61А - 84 номерлы йортлары, КамАЗ урамы, Яңа урамы, Таҗиев урамы, Почта урамының 1 - 32 номерлы йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;
- халык җыенының өченче этабын 2022 елның 25 октябрендә 14 сәгать 00 минутта Тукай урамы, 110 йорт янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Тукай урамының 85 - 161 номерлы йортлары, Почта урамының 33 - 65 номерлы йортлары, Шәле тыкрыгы урамы буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- халык җыенының дүртенче этабын 2022 елның 25 октябрендә 16 сәгать 00 минутта Кызыл Йолдыз урамы, 15 йорт янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Кооператив урамы, Кызыл Йолдыз урамының 1-38 номерлы йортлары, Һади Такташ урамының 1-41 номерлы йортлары, Хәйруллин урамы, Кәвәл урамы буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- халык җыенының бишенче этабын 2022 елның 26 октябрендә 10 сәгать 00 минутта Һади Такташ урамы, 58 йорт янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Кызыл Йолдыз урамының 39-84 номерлы йортлары, Һади Такташ урамының 42-84 номерлы йортлары, Муса Җәлил урамы буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- халык җыенының алтынчы этабын 2022 елның 26 октябрендә 12 сәгать 30 минутта Дуслык урамы, 27 йорт янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Дуслык урамы, Чокыр урамы буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- халык җыенының җиденче этабын 2022 елның 26 октябрендә 14 сәгать 00 минутта Ленин урамы, 26 йорт янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Совет урамы, Ленин урамы, Вахитов урамының 1-37 номерлы йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- халык җыенының сигезенче этабын 2022 елның 26 октябрендә 16 сәгать 00 минутта Казан урамы, 12 йорт янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Казан урамы, М.Шәйхиева урамы, Г.Сәфиуллина урамы, Ф.Сафин урамы, М.Мәхәмәтҗанова урамы, Җиңү урамы, Шатлык урамы, Кыр урамы, Вахитов урамының 38-74 номерлы йортлары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез, 2023 елда Шәле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 группа инвалидларны, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылар, Бөек Ватан сугышында һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарын, сугыш һәм хәрби хәрәкәтләрендә катнашучыларны, 80 яшькә җиткән гражданнарны, махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.2. Шәле авыл җирлеге ТатЦИК исемендәге авылда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә:

Гражданнар җыенын 2022 елның 27 октябрендә 13.00 сәгатьтә Совет урамы, 12а йорт адресы буенча урнашкан кибет бинасы янында уздырырга.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез, 2023 елда ТатЦИК исемендәге торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 группа инвалидларны, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләрендә

катнашучылар, Бөек Ватан сугышында һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарын, 80 яшькә җиткән гражданнарны, махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Шәле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы
Шәле авыл җирлеге башлыгы И.Р. Әхмәтҗанов